ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЛТАСИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 45, пгт Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 45 нче йорт, Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-52-15, факс: (84368) 2-54-44. E-mail: Bltgp.Blt@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 декабрь 2020 нче ел № 58

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 03.07.2020 № 32 карарлары нигезендә **карар бирәм:**

1.Расларга:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына ачык аукцион комиссиясе составы 1 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына ачык аукцион комиссиясе турындагы нигезләмә 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына ачык аукцион уздыру турында хәбәрнамәнең үрнәге;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына ачык аукцион документациясенең үрнәге;

1. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Балтач муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//baltasi.tatar.ru.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: И.Д.Габдрахманов

**КИҢӘШЕЛДЕ:**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - Галимуллин И.С.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе – Фатхутдинов И.М.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары – Закирова Ф.А.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы - Фатыхов Р.С.